РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БИЛЯР-ОЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БИЛЯР-ОЗЕРО
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | Биляр-Озеро ав. | КАРАР

«26» октябрь 2020 | № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Зирекле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр - Озеро авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 21 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 34Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Мәктәп урамы 1-64, Яшьләр урамы 2-54нче йортларда яшәүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 22 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Мәктәп урамы, 34Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты янында Кыр урамы 1-41, Елга урамы 1-43нче йортларда яшәүче гражданнар өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә туры китерү эшләрен үткәрү;

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр товарлар, сатып алу;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен цистерна сатып алу;

- янгын сүндерү өчен гидрант сатып алу һәм урнаштыру».

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы И.М.Шәрәфетдинов